Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз дүртенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

31 август, 2023 ел № 254

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Кощаково авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә, гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм 2023 елның 22 августындагы «Кощаково авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәсен исәпкә алып **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2021 елның 24 ноябрендәге 123 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Кощаково авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (Советның 2022 елның 30 мартындагы 145 номерлы, 2022 елның 8 декабрендәге 202 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Кощаково авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында әлеге карарны территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов